**Казан шәһәре Башкарма комитетының**

2024 елның 3 июлендәге 2847 номерлы карары

# Казан шәһәренең Идел буе һәм Вахитов районнарында җир кишәрлекләренә ачык сервитут билгеләү турында

1. Әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталары нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган ачык сервитутның характеристикасы:

- йогынты ясала торган мәйдан – 189 136 кв.м;

- үзләренә карата хокуклар чикле булган җир кишәрлекләренең кадастр номерлары: 16:50:080704:22, 16:50:080703:546, 16:50:080704:17, 16:50:080704:19, 16:50:081012:3, 16:50:000000:11405, 16:50:000000:21254, 16:50:080704:3, 16:50:000000:18343, 16:50:180102:5, 16:50:080704:8, 16:50:080704:23, 16:50:080704:292, 16:50:080704:75, 16:50:080704:24, 16:50:000000:21222, 16:50:000000:18334, 16:50:000000:18530, 16:50:080703:16;

- урнашу урыны: Идел буе һәм Вахитов районнары, Казан шәһәре;

- урнаштыру максаты: әгәр күрсәтелгән объектлар федераль, төбәк яисә җирле әһәмияттәге объектлар булса, электр челтәре хуҗалыгы объектларын, җылылык челтәрләрен, су үткәрү челтәрләрен, су чыгару челтәрләрен, элемтә линияләрен һәм корылмаларын, газ белән тәэмин итү системаларының линия объектларын, нефть үткәргечләрне һәм нефть продуктларын үткәргечләрне, аларның аерылгысыз технологик өлешләрен төзү, реконструкцияләү, файдалану, капиталь ремонтлау;

- билгеләү вакыты: 3 ел;

1.2. гариза бирүче: «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Капиталь төзелеш һәм реконструкция идарәсе» муниципаль казна учреждениесе

1.3. билгеләү нигезләре: гариза бирүченең мөрәҗәгате, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Россия Федерациясе Җир кодексының V.7 бүлеге, Россия Федерациясе Җир кодексының 23 статьясы, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 12 апрелендәге 1541 номерлы «Яңа Портовая» гидротехник корылмасы» җирле әһәмияттәге линия объекты территориясен планлаштыру проектын (2 нче этап) раслау турында»гы карары.

2. «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталары нигезендәге чикләрдә ачык сервитутның йогынты ясау өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗә-

гать итәргә.

3. Әлеге карарның 2 номерлы кушымтасыннан кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.


4. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче Р.Г.Гафаров**

1 номерлы кушымта
Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 3 июлендәге
2847 номерлы
карары белән расланды

**Җир кишәрлекләренең бер өлешенә**
**ачык сервитут йогынты ясый торган өлкә чикләре**




Масштаб 1:15000
Координаталар системасы: МСК-16

| Шартлы билгеләр: | |
|---|---|
| 1 | яңа ясалган характерлы нокта |
| | билгеләнә торган сервитут чиге |
| | булган җир кишәрлекләренең чиге |
| | территориялардән файдалануның махсус шартлары булган зоналар (гамәлдәге) |
| | кызыл линияләр (гамәлдәге) |
| | капиталь төзелеш объектлары (мәйданлы) |
| 16:50:180102, 16:50:081012, 16:50:080703, 16:50:080704 | кадастр кварталы |
| 16:50:080704:22, 16:50:080703:546, 16:50:080704:17, 16:50:080704:19, 16:50:081012:3, 16:50:000000:11405, 16:50:000000:21254, 16:50:080704:3, 16:50:000000:18343, 16:50:180102:5, 16:50:080704:8, 16:50:080704:23, 16:50:080704:292, 16:50:080704:75, 16:50:080704:24, 16:50:000000:21222, 16:50:000000:18334, 16:50:000000:18530, 16:50:080703:16 | үзенә карата хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры |